**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2022-2023 нче уку елы 4 нче сыйныф**

**Максималь балл – 30**
**Үткәрү вакыты – 120 минут**

**Текстны укыгыз.**

**Йолдыз**

Үзәнлектә җилләр уйнап йөри,
Яфракларны куып түбәнгә.
Маңгаенда кызыл йолдыз яна,
Кем ул күмелеп йоклый үләнгә?
Кем ул күмелеп йоклый?
Милләте кем?

Кай өлкәдән? Кайсы авылдан?
Бу сугышка кайчан алынган?
Балалары бардыр, бәлки, аның,
Яшь егеттер, бәлки, кем белгән.
Ләкин безгә менә шунсы ачык:
Туган җире өчен ул үлгән.

*Сибгат Хәким*

**I. Тестны эшләгез. (9 балл)**

1. Текстта [ғ] авазы кергән ничә сүз бар?
а) 4
ә) 5
б) 8

2. Йолдыз сүзенең дөрес бирелгән транскрипциясен табыгыз.
а) йолдыз – [йолдыз]
ә) йолдыз – [йолдыс]
б) йолдыз – [йолдоз]

3. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез.
а) яфрак
ә) туган
б) йоклый

4. Калын һәм нечкә сузык авазларның парлары дөрес булган рәтне табыгыз.
а) [а] – [ә], [о] – [ө], [у] – [ү], [ы] – [и]
ә) [а] – [ә], [о] – [ө], [у] – [ү], [ы] – [э]
б) [а] – [ә], [о] – [э], [у] – [ү], [ы] – [ө]

5. Басым дөрес куелган рәтне билгеләгез.
а) ба́рмый, нә́рсә, китте́ме, ру́сча
ә) а́шамый, нинди́, ки́ләме, татарча́
б) сөйләми́, кайсы́, барамы́, и́нлизчә

6. *Түбән* сүненең антонимын табыгыз.
а) уңда
ә) югары
б) янәшә

7. *Улү* сүзенең синонимын билгеләгез.
а) түзү
ә) яшәү
б) вафат булу

8. Составында форма ясагыч кушымча булган сүзне билгеләгез.
а) милләттәш
ә) үзәнлекләр
б) йокла

9. Ясалма нигезле сүзне билгелә.
а) авыл
ә) авылга
б) авылдаш

## II. Теоретик бирем. (5 балл)

**Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр турында языгыз һәм мисаллар китерегез**.

## III. Гамәли-иҗади бирем. (16 балл)

1. Туган илне саклау турында текст төзеп языгыз (10 җөмлә). (10 балл)
2. *Туган* сүзенә язмача фонетик анализ ясагыз. (6 балл)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2022-2023 нче уку елы**
**5 нче сыйныф**

**Максималь балл – 38**
**Үткәрү вакыты – 120 минут**

**Текстны укыгыз.**

**Кабан күле**

Нинди иркенлек! Без көймәдә барабыз. Күлнең бу ягы күбрәк ошый. Теге ягында шәһәр, шау-шу иде. Бу якта авыл, кыр, табигать һәм тынлык. Әнә теге якта Әмәт тавы сузылып ята. Бу якта агачлыклар яр буйларын каплый. Зәңгәр күк йөзендә ак болыт кисәкләре йөзә. Болытлар күккә яз төсе бирәләр. Кыш көне мондый болытлар булмый бит. Әнә безнең баш очыбызда ике тилгән әйләнә. Вакыт-вакыт аларның калтыравыклы тавышларын колаклар ишетә.

Кояш кыздыра. Рәшид, ишкәкләрне ташлап, пәлтәсен салды. Ул тирә-якка карый. Ике ел гомер аны бер дә үзгәртмәгән. Аның йөзе ак, күзләре зур, дулкынланып тора торган чәчләре шомырт кебек кап-кара. Көлгәндә тип-тигез ак тешләре күренә.

*Г. Рәхимнән*

**I. Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Рәт гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез.
а) агачлык
ә) болыт
б) табигать

2. *Голосовые связки* татарча ничек була?
а) йоткылык
ә) кече тел
б) тавыш ярылары

3. *Гомер* сүзенең дөрес бирелгән транскрипциясен билгеләгез.
а) [ғөмэр]
ә) [ғомөр]
б) [ғөмөр]

4. Тексттан *тынлык* сүзенең антонимын табып языгыз.
___________

5. *Тилгән* сүзе русча ничек була?
а) коршун
ә) ястреб
б) орел

6. Сүзләрнең алфавит тәртибендә язылган вариантын билгеләгез.
а) ак, ел, көймә, күк, күл, шәһәр, шомырт, чәч, яз
ә) ак, ел, көймә, күл, күк, чәч, шәһәр, шомырт, яз
б) ак, ел, көймә, күк, күл, чәч, шәһәр, шомырт, яз

7. Тексттан рус теле аша француз теленнән кергән сүзне табыгыз.
_______________________________________________

8. Хәбәре сыйфат сүз төркеме белән белдерелгән җөмләне күчереп языгыз.
_______________________________________________

9. *Вакыт-вакыт аларның калтыравыклы тавышларын колаклар ишетә* җөмләсендә хәлне билгеләгез.
а) вакыт-вакыт
ә) аларның
б) тавышларын

10. *Вакыт-вакыт аларның калтыравыклы тавышларын колаклар ишетә* җөмләсендә тәмамлык –
а) вакыт-вакыт
ә) колаклар
б) тавышларын

## II. Теоретик бирем (8 балл)

**Алынма сүзләр турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

## III. Гамәли-иҗади бирем (20 балл)

1. "*Язгы көн*" темасына хикәя төзеп языгыз. (10 җөмлә) (10 балл)
2. *Язгы* сүзенә язмача фонетик анализ ясагыз. (4 балл)
3. *Баш* сүзеннән дүрт тамырдаш сүз ясап языгыз. (3 балл)
4. *Кисәкләре* сүзен мәгънәле кисәкләргә таркатыгыз. (3 балл)

*Зәңгәр күк йөзендә ак болыт **кисәкләре** йөзә.*

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2022-2023 нче уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 33**
**Үткәрү вакыты – 150 минут**

**Текстны укыгыз.**

**Анам**

Буран котыра. Тәрәзә алдына яткан сары эт зур һәм кара күзләре белән кешеләрне каршы ала, киткәннәрне моңлы күзләре белән озата. Ул гүя кайгылы иде.

Ананың йөзе саргайган, күзләре эчкә баткан, кул һәм аягы салкын, күкрәге авыр сулый. Ул күзләре белән нидер эзли, кемнедер күрәсе килә. Ул:

– Килмәдеме? – дип сорый иде. Кызы Фатыйма бертуктаусыз елый.
Өч атнадан бирле авырып яткан анасы узган кич беренче мәртәбә төн уртасында:

– Фатыйма! Тор, тизрәк чыгып кара. Килмәдеме? – дип, аны куркыткан иде. Менә шуннан бирле һаман көтә. Шулай да һаман әлеге «килмәдеме» дигән сүзне эчкә баткан күзләре, күгәргән иреннәренең хәрәкәте белән аңлатырга тырыша иде. Әй мәрхәмәтле ана!

Аның инде кул, аяклары сизми, кузгалмый, салкын һәм авыр ташлар шикелле тарталар. Ул бик әкрен генә төпсез һәм салкын диңгез төбенә төшеп бара...

Чү! Ишек алдында кемнәр? Ишек ачылды. Керделәр. Ике кеше. Берсе катып калды, тезләнде. Елаган тавыш белән:

– Анам! – дип кычкырып җибәрде дә карчыкның күкрәгенә йөзен куеп елый башлады. Бу Мостафа иде.

*Ш. Камалдан*

**I. Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Татар телендә ничә кыска сузык аваз бар?
   а) 3
   ә) 4
   б) 6

2. Ясалу урыны буенча **[**ч**]** тартыгы –
   а) ирен-теш тартыгы
   ә) кече тел тартыгы
   б) тел алды тартыгы

3. *Елаган* сүзенең дөрес язылган транскрипциясен билгеләгез.
   а) [йыла°ған]
   ә) [йылаған]
   б) [йылаган]

4. [у] сузык авазына дөрес бирелгән характеристиканы табыгыз.

а) [у] – арткы рәт, кыска, иренләшкән сузык аваз

ә) [у] – алгы рәт, озын, иренләшкән сузык аваз

б) [у] – арткы рәт, озын, иренләшкән сузык аваз

5. Тексттан чикләү мәгънәсен белдергән кисәкчә булган җөмләне күчереп языгыз.

6. Татар телендәге рус алынмаларын билгеләгез.

а) спорт, чемпион, кекс

ә) эскәтер, эшләпә, сумала

б) вермишель, макарон, матрос

7. Ымлык булган җөмләне билгеләгез.

а) Ул гүя кайгылы иде.

ә) Менә шуннан бирле һаман көтә.

б) Чү! Ишек алдында кемнәр?

8. *Аның инде кул, аяклары сизми, кузгалмый, салкын һәм авыр ташлар шикелле тарталар* җөмләсеннән тиңдәш кисәкләрне күчереп языгыз.

__________________________________________________________________________

9. *Паспорт, метро, парад* сүзләре

а) рус алынмалары

ә) француз теленнән кергән сүзләр

б) инглиз теленнән кергән сүзләр

## II. Теоретик бирем. (5 балл)

**Сүз төзелеше, тамыр һәм кушымчалар турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

## III. Гамәли-иҗади бирем. (18 балл)

1. "*Бик сагынсам сине, күккә карыйм, Син үзең дә ай күк, и әни!"* дигән темага текст төзеп языгыз. (10 җөмлә) (10 балл)
2. *Буран* сүзенә фонетик анализ ясагыз. *(5 балл)*
3. Фигыльләрнең нигезеннән хәзерге заман хикәя фигыльләр ясагыз. (3 балл)

Эшлә-, укы-, бие-, җырла-, мен-, җый-, төзе-, сөйлә-, кал-.

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2022-2023 нче уку елы 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**
**Үткәрү вакыты – 150 минут**

**Текстны укыгыз.**

**Солдатлар**

Без барыбыз да бер яшьтәрәк. Бик яшь тә түгел, ләкин карт дип тә әйтеп булмый әле безне. Әйе, карт түгел, безнең өйләребездә хатыныбыз, балаларыбыз бар. Ярты күңел биредә булса, яртысы алар янында.

Без хәзер фронтка якын гына бер җирдә резервта торабыз. Димәк, вакыт күп, ә эш аз. Дөрес, кайчагында фриц, килеп, безнең өскә бомбалар ыргытып китә. Ләкин без инде аңа күнеккән.

Тышта яз. Агачлар чәчәктә. Өй кыегында – сыерчыклар, һавада – тургайлар. Шундый тыныч, шундый рәхәт. Якында гына сугыш барганына ышанасы да килми. Кичә генә безнең өскә туп ядрәләре ява иде. Ә бүген барысы да әкренләп онытыла башлады. Ә иртәгә, бәлки, бөтенләй дә онытылыр.

Кайвакыт без шулай яшел чирәм өстенә түгәрәкләнеп утырабыз да кесәдә аунаган иске хатларны кат-кат укыйбыз, карточкаларны чыгарып карыйбыз. Бу безнең өчен зур бер юаныч була иде.

*И. Газидан*

**I. Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. [а] тартык авазына дөрес бирелгән характеристиканы табыгыз.
   а) [а] **–** иренләшкән, түбән күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы
   ә) [а] **–** иренләшмәгән, урта күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы
   б) [а] – иренләшмәгән, түбән күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы

2. Ясалу урыны буенча **[й]** тартыгы –
   а) тел арты тартыгы
   ә) тел уртасы тартыгы
   б) тел алды тартыгы

3. Ясалу ысулы буенча **[й]** тартыгы –
   а) йомык
   ә) өрелмәле
   б) ярымйомык

4. [р] тартык авазына дөрес бирелгән характеристиканы табыгыз.
   а) [р] – парсыз яңгырау, сонор, калтыраулы, тел алды, авыз тартыгы
   ә) [р] – парсыз яңгырау, сонор, ярымйомык, тел арты, авыз тартыгы
   б) [р] – парсыз яңгырау, йомык, тел алды, авыз тартыгы

5. Җөмләгә төшеп калган дифтонгларны языгыз.

Мал_ ж_ көне а_лга к_та.

6. Күчерелмә мәгънәле сүз булган сүзтезмәне табыгыз.

а) зәңгәр яулык

ә) зәңгәр бәхет

б) зәңгәр күк

7. Ойконимны билгеләгез.

а) Чистай шәһәре

ә) Айгөл

б) Кара диңгез

8. Тезмә кушма җөмләне билгеләгез.

а) Дөрес, кайчагында фриц, килеп, безнең өскә бомбалар ыргытып китә.

ә) Кайвакыт без шулай яшел чирәм өстенә түгәрәкләнеп утырабыз да кесәдә аунаган иске хатларны кат-кат укыйбыз, карточкаларны чыгарып карыйбыз.

б) Димәк, вакыт күп, ә эш аз.

9. *Без хәзер фронтка якын гына бер җирдә резервта торабыз* җөмләсендә *резерв* сүзенең аңлатмасын билгеләгез.

а) солдат, рядовой гаскәри

ә) дәүләтнең барлык кораллы көчләре

б) гаскәри хезмәттән запаска җибәрелгән кешеләр

10. *Без карточкаларны чыгарып карыйбыз* җөмләсендә *карточкаларны* сүзенең дүрт грамматик мәгънәсен языгыз.

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

## II. Теоретик бирем. (15 балл)

**Омонимнар турында языгыз һәм мисаллар китерегез.**

## III. Гамәли-иҗади бирем. (25 балл)

1. “*Солдатка хат”* дигән темага текст төзеп языгыз. (10 җөмлә) (10 балл)
2. *Юаныч* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (6 балл)
3. *Ак* һәм *кара* сүзләре метафора булып килерлек итеп, икешәр җөмлә төзегез. (4 балл)
4. Бирелгән фразеологизмнарның русча вариантларын языгыз. (5 балл)

Телеңне йотарсың – ________________________

алтын куллы – ________________________

бер чыбыктан сөрелгән – ____________________

кәкре каенга терәтү – _______________________

уртак тел табу – ____________________________

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2022-2023 нче уку елы 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**
**Үткәрү вакыты – 150 минут**

**Текстны укыгыз.**

– Минем бит әле сезгә күрсәтәсе бер әйберем бар, – диде Бәдретдин.

Ул шүрлектән кечкенә генә скрипка алды, әмма бу кулдан ясалган, буялмаган, начар бер скрипка иде. Бәдретдин скрипканы кулына алуга, без аңа гаҗәпләнеп карадык.

– Кайдан бу синдә?

– Үзем ясадым, – диде Бәдретдин һәм скрипканың кылларын көйләргә тотынды. Без аның кубызда уйнавын, мандолина чиерткәләвен белә идек.

– Әй, Бәдри, нигә моңарчы яшердең? – дидек без. – Мәдрәсәдә Сәгыйть скрипкасын алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

– Оста барда кулың тый! – диде ул, тыйнак кына елмаеп.

Скрипка озак яткан, шуңа күрә Бәдретдин аны шактый озак көйләде. Без аның әнисенә карадык, әмма ана үзенең улына бик яратып, сокланып карап утыра иде. Иң яхшы укучының әнисе бит ул!

*Ә. Еникидән*

**Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Басым соңгы иҗеккә төшми торган сүзләрне билгеләгез.
   а) яшердең, мәдрәсәдә
   ә) буялмаган, кайдан
   б) скрипкада, чиерткәләвен

2. *Бәдретдин* сүзендәге сузык авазлар –
   а) иренләшмәгән, алгы рәт сузыклары
   ә) иренләшкән, алгы рәт сузыклары
   б) иренләшмәгән, арткы рәт сузыклары

3. *Бәдри* сүзендәге сузык авазлар –
   а) [ә] - озын сузык, [и] - кыска сузык
   ә) икесе дә кыска сузык
   б) икесе дә озын сузык

4. Фарсы теленнән алынган компонентлар булган сүзләрне билгеләгез.
   а) даруханә, хәбәрдар
   ә) мәктәп, әдәбият
   б) чәчәкле, сәламәтлек

5. *металл* сүзенә тартым кушымчасы ялгануның дөрес вариантын билгеләгез.

   а) металлам
   ә) металлым
   б) металым

6. *календарь* сүзенә тартым кушымчасы ялгануның дөрес вариантын билгеләгез.

   а) календаребыз
   ә) календаребез
   б) календарыбыз

7. *Бәдретдин скрипканы кулына алуга, без аңа гаҗәпләнеп карадык* җөмләсе –

   а) гади җөмлә
   ә) иярченле кушма җөмлә
   б) тезмә кушма җөмлә

8. *Без аның әнисенә карадык, әмма ана үзенең улына бик яратып, сокланып карап утыра иде* җөмләсе –

   а) синтетик иярченле кушма җөмлә
   ә) тезмә кушма җөмлә
   б) аналитик иярченле кушма җөмлә

9. *Без аның кубызда уйнавын, мандолина чиерткәләвен белә идек* җөмләсендә мандолина сүзе җөмләнең кайсы кисәге?

   а) тәмамлык
   ә) ия
   б) хәл

10. Кайсы кагыйдә дөрес түгел?

   а) фигыльнең юклык кушымчасына (-ма,-мә) басым төшми
   ә) кайбер күрсәтү һәм сорау алмашлыкларында басым беренче иҗеккә төшә
   б) II зат боерык фигыльләрдә басым соңгы иҗеккә төшә

## II. Теоретик бирем. (10 балл)

**Пассив лексика турында языгыз һәм бишәр мисал китерегез.**

## III. Гамәли-иҗади бирем. (30 балл)

1. *Чиерткәләвен* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (15 балл)
2. Тексттагы туры сөйләмле җөмләләрне кыек сөйләмгә әйләндереп языгыз. (5 балл)
3. “Оста барда кулың тый!” темасына 10 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. (10 балл)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2022-2023 нче уку елы 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 40**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**

**Текстны укыгыз.**

(1) Халисә, почтага килгән хатларны барлаганда, сәер бер хатка тап булды. (2) Зәңгәр кыңгыраулар рәсеме ясалган конверт тышына басма хәрефләр белән «Татарстан, Алансу, Сәйдә әбигә» дип язылган.

Авылларында ике Сәйдә бар: берсенә кырык биш яшьләр булыр, ә икенчесе сиксәнгә җитеп килә. Кемгә булыр икән бу хат? Балалар кулы белән язылган, фамилиясе дә юк. Халисә хатлар салынган сумкасын иңбашына элде дә велосипедына утырып чыгып китте.

Сәйдә карчык үзенең Казан каласында беркеме дә юклыгын әйтте.

– Юк, сеңлем, миңа түгел, Мөхәммәтҗан Сәйдәсенәдер. Аның балалары Казанда яши, – дип, Халисәне борып җибәрде. Мөхәммәтҗан Сәйдәсенең өе балалар тавышыннан гөр килеп тора иде. Улының да, кызының да балалары җәйге ялга авылга кайтканнар, качышлы уйнап яталар.

*Р. Шәйдуллина-Мураттан*

**Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Әдәби әйтелешне үзгәртеп сөйләүнең сәбәбен билгеләгез.
а) орфография кагыйдәләрендә бирелгән аңлатмаларга ияреп, дөрес язылганны ялгыш уку
ә) сүзләрдә басымның соңгы иҗеккә төшмәскә мөмкин булуы
б) сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен һәр очракта да бер генә төрле язу

2. Төшерелмә дифтонглар булган сүзләрне билгеләгез.
а) авыл, тавыш, өе
ә) кыңгырау, Сәйдә, уйнап
б) яши, сәер, юклыгын

3. Йомык тартык авазлар гына булган сүзне билгеләгез.
а) тап
ә) сиксән
б) кил

4. Тел алды тартыклары гына булган сүзне билгеләгез.
а) улының
ә) кайткан
б) тышына

5. Рәт гармониясе сакланмаган сүзләр генә булган вариантны билгеләгез.
а) Халисә, конверт, иңбашына
ә) сәер, Мөхәммәтҗан, яши
б) почта, фамилия, велосипед

6. Ирен ассимиляциясенә караган мисалны билгеләгез.
а) кайтканнар
ә) борып
б) унбер

7. Кушымча ялгау юлы белән ясалган сүзләр булмаган рәтне билгеләгез.
а) басма, Алансу
ә) тавышыннан, иңбашына
б) Мөхәммәтҗан, җәйге

8. Текстның 1, 2 җөмләләрендә кулланылган сыйфат фигыльләрне билгеләгез.
а) килгән, ясалган
ә) язылган, булды
б) сәер, басма

9. *Кемгә булыр икән бу хат?* җөмләсендә *бу* сүзе җөмләнең кайсы кисәге?
а) аергыч
ә) ия
б) хәл

10. *Улының да, кызының да балалары җәйге ялга авылга кайтканнар, качышлы уйнап яталар* җөмләсенең төрен билгеләгез.
а) гади җөмлә
ә) тезмә кушма җөмлә
б) иярченле кушма җөмлә

**II. Теоретик бирем. (10 балл)**

**Рәвеш, аның төркемчәләре турында языгыз һәм өчәр мисал китерегез.**

**III. Гамәли-иҗади бирем. (20 балл)**

1. *Кемгә булыр бу билгесез хат?* җөмләсендәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз. (5 балл)

2. Алфавитта урнашу тәртибенә карап, хәрефләрне табыгыз, яшерелгән мәкальне языгыз. (7 балл)

3, 1, 15, 1, 6, 1, 17   3, 2, 28, 7, 24, 7, 18   3, 25, 15, 23,1
14, 1, 22, 24   14, 20, 17, 7, 18, 6, 2   39, 32, 36   12, 24, 2, 22

______________________________________________________________

3. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. (8 балл)

Ванька свернул вчетверо исписанный лист и вложил его в конверт, купленный накануне за копейку... Подумав немного, он умокнул перо и написал адрес:

На деревню дедушке.

Потом почесался, подумал и прибавил: «Константину Макарычу».

Довольный тем, что ему не помешали писать, он надел шапку и, не набрасывая на себя шубейки, прямо в рубахе выбежал на улицу...

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2022-2023 нче уку елы 10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 50**
**Үткәрү вакыты – 180 минут**

**Текстны укыгыз.**

Карлыгачны, елдагыча, колхозның хуҗалык атлары, юртаклары белән бергә, йөк машинасының калын librar такталар белән әйләндереп алынган әрҗәсенә менгергәч, малай кабинага, шофёр агай янына чүмәште.

– Быел да җиңеп кайтыргамы исәп? – Чигә чәчләренә мул булып чал йөгергән күрше агай, мыек чолгыйларына кадәр балкытып, йөзен тутырып елмайды.

– Маладис син, пар-рин, ма-ла-дис! Беркемгә дә сер бирмисең, әй... Авыл гөж килә, Карлыгачны кем урларга җыенганын авыз тутырып сөйли. Атаң гына... «Каракны күзем белән күрмәдем», дип, киресенә катып тора.

Малай бик батыр кыяфәттә борынын чөйде:

– Мин курыкмыйм, ул карак прсидән дә, өстәгеләрдән дә курыкмыйм.

Карлыгачны алам да Җиләктау чокырына качам да китәм, берәү дә табалмый! Карлыгачка тиеп кенә карасыннар!..

– Сабантуйлар синең кебек малайларныкы инде ул, әйе... – Агай мәзәк кенә итеп борынын җыерды.

*А. Әхмәтгалиевадан*

**Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. Тартык авазларга бирелгән характеристакаларның хаталысын билгеләгез.
а) [w] – ирен-ирен, өрелмәле
ә) [н] – тел алды, йомык
б) [к] – кече тел, йомык

2. Басым ахыргы иҗегенә төшә торган сүзләрне билгеләгез.
а) каракны, малайларныкы
ә) елдагычы, кабинага
б) күрмәдем, курыкмыйм

3. Орфографик принципларга туры килгән мисалларны табыгыз.
а) фонетик принцип
ә) морфологик принцип
б) тарихи-традицион принцип
в) график принцип

1) әнкәй, унбер
2) майор, биология
3) тәрәзә, гөл
4) 4 нче йорт, җылылык 18° тан югары

4. Хәл фигыльләр рәтен билгеләгез.
а) менгергәч, балкытып
ә) кайтыргамы, йөгергән
б) урларга, курыкмыйм

5. Фразеологик сүтезмәне билгеләгез.
а) мыек чолгыйлары
ә) киресенә катып тора
б) шофёр агай янына чүмәште

6. *чүмәште* сүзенең синонимын билгеләгез.
а) егылды
ә) утырды
б) чүгәләде

7. *көймә борыны* сүтезмәсе күчерелмә мәгънәнең кайсы төренә карый?
а) метафора
ә) метонимия
б) синекдоха

8. Фарсы теленнән кергән алынма сүзләрне билгеләгез.
а) карлыгач, малай, карак, чокыр, юртак
ә) тәртип, хат, рәсем, сәгать, каләм
б) сәүдә, шәһәр, каһарман, гәүһәр, әсәр, әсир

9. *Малай бик батыр кыяфәттә борынын чөйде* җөмләсендә *борынын* сүзе җөмләнең кайсы кисәге?
а) тәмамлык
ә) ия
б) хәл

10. Хәбәр игелә торган фикерне эмоциональ яктан бәяләүне белдерә торган модаль сүзләрне билгеләгез.
а) гаҗәп, кызганыч, үкенеч
ә) әлбәттә, һичшиксез, бәхәссез
б) бәлки, бугай, мөгаен

## II. Теоретик бирем. (5 балл)

**Аваз иялтемнәре турында языгыз һәм алты мисал китерегез.**

## III. Гамәли-иҗади бирем. (35 балл)

1. *елдагыча* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (10 балл)
2. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз (10 балл)

Карлыгачны, елдагыча, йөк машинасының калын такталар белән әйләндереп алынган әрҗәсенә менгергәч, малай кабинага, шофёр агай янына чүмәште.

Карлыгачны алам да Җиләктау чокырына качам да китәм, берәү дә табалмый!

3. “Ат чабышы – Сабантуйның күрке” темасына 15 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. (15 балл)

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2022-2023 нче уку елы 11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 46**
**Үткәрү вакыты – 180 минут**

**Текстны укыгыз.**

Ниһаять, чират Рудольф Нуриевка җитте.

– Абитуриент Нуриев! – дип кычкырды сәркатип.

Ул сынау залына килеп кергәндә, озын, зифа буйлы бер хатын, аягүрә басып, комиссия әгъзаларына нидер аңлата иде. Комиссия әгъзалары өстәл арасында утыра, алларында кәгазь битләре, каләмнәр, графинда су. Көзгеле зур зал, залның аргы башында рояль янында музыкант утыра. Комиссия артындагы урындыкларда тамашачы, укытучылар, училищеда эшләүче башка хезмәткәрләрдер, ахрысы, кергән бер кызга, егеткә алар да тикшереп карый.

Каушата, куркыта. Тез буыннары калтырый.

Аягүрә торучы әлеге нәфис ханым боерулы тавыш илә әйтте, Нуриевка түгел, комиссиягә әйтте булса кирәк:

– Нуриев Рудольф Хамитович, 1938 елда туган!

«1938 елда туган» дигән сүзләргә ханым аеруча басым ясап, «Игътибар итегез, ул инде училищега керү вакытыннан узып киткән, ул инде картаеп бара» дигән мәгънә салып әйтте кебек.

Комиссиядәгеләр үзара чыш-пыш килә башлады. Рудольфның табанына шом йөгерде: «Болар мине алмаска азаплана, ахрысы», – дип уйлады ул.

– Ну-с! – диде кырыс ханым. – Раз сез шулкадәр ераклардан килгәнсез икән, күрсәтегез һөнәрегезне, карап багыйк бер!

Бу сүзләрдә дә «Ерак арадан килгәнең өчен генә сине тикшереп карыйбыз!» дигән мәгънә ята иде сыман.

*Р. Батулладан*

**Тестны эшләгез. (10 балл)**

1. *соңгылар* сүзендәге сузык авазларга бирелгән характеристикаларның хаталысын билгеләгез.

а) [о] — иренләшкән, урта күтәрелешле, кыска, арткы рәт сузыгы
ә) [ы] — иренләшкән, урта күтәрелешле, кыска, арткы рәт сузыгы
б) [а] — иренләшмәгән, түбән күтәрелешле, озын, арткы рәт сузыгы

2. Гарәп-фарсы алынмаларының рус алынмалары һәм интернациональ сүзләр белән бирелгән синонимнарын тоташтырыгыз.

| | |
|---|---|
| җәдвәл | республика |
| җөмһүрият | логика |
| әмер | типография |
| мантыйк | приказ |
| матбуга | таблица |

3. Билгесезлек алмашлыгын билгеләгез.

а) болар
ә) нидер
б) беркем

4. Инфинитивны билгеләгез.
а) кергәндә
ә) алмаска
б) узып киткән

5.  Сыйфат фигыльне билгеләгез.
а) эшләүче
ә) боерулы
б) багыйк

6. *аягурә* рәвешенең төркемчәсен билгеләгез.
а) сәбәп-максат
ә) күләм-чама
б) саф

7. Затланышсыз фигыльләрне билгеләгез.
а) тикшереп, керү
ә) каушата, багыйк
б) булса, күрсәтегез

8. Ярдәмлек сүз төркемнәрен билгеләгез.
а) кисәкчәләр, ымлыклар
ә) бәйлекләр, теркәгечләр
б) аваз ияртемнәре

9. *Комиссиядәгеләр үзара чыш-пыш килә башлады* җөмләсендә комиссиядәгеләр сүзе –
а) урын хәле
ә) ия
б) аергыч

10. *Ул сынау залына килеп кергәндә, озын, зифа буйлы бер хатын, аягүрә басып, комиссия әгъзаларына нидер аңлата иде* җөмләсенең төрен билгеләгез.
а) синтетик иярченле кушма җөмлә
ә) аналитик иярченле кушма җөмлә
б) тезмә кушма җөмлә

## II. Теоретик бирем. (10 балл)

**Тезмә кушма җөмләләр турында языгыз һәм һәр төренә өчәр мисал китерегез.**

## III. Гамәли-иҗади бирем. (26 балл)

1. Җөмләгә синтаксик анализ ясагыз (5 балл)

Ул сынау залына килеп кергәндә, озын, зифа буйлы бер хатын, аягүрә басып, комиссия әгъзаларына нидер аңлата иде.

2. Татар халык мәкален языгыз. (6 балл)

([г]ның саңгырау пары) е ([ж]ның саңгырау пары) е ([к]ның яңгырау пары) ә и (парсыз яңгырау, кече тел тартыгы) (саңгырау, тел арты тартыгы) и (калтыраулы тартык) ә (яңгырау, тел арты тартыгы) е — я ([қ]ның яңгырау пары) ы (яңгырау, ирен-ирен тартыгы) (яңгырау, тел алды тартыгы) ы (тел уртасы тартыгы) ө ([с]ның яңгырау пары), ([ч]ның яңгырау пары) ы (яңгырау, тел алды тартыгы) ы ([з]ның саңгырау пары) ү ([с]ның яңгырау пары).

3. “Сынау” темасына 15 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. (15 балл)